Иптәшләр!

Совет дәүләтенең 1924-25 елдан башлап авыл хуҗалыгын үзгәртеп кору турында бер-бер артлы төрле карарлары чыкты, крестьян комитетлары төзелде, крестьяннарны берләштереп эшләтү өчен колхозлар-совхозлар төзү турында сүзләр алып бара башланды. Ул гомер-гомер буена бер формада яшәп килгән крестьяннарның тормышын һәм культурасын җимерде, дини бәйрәмнәрен генә түгел, милли бәйрәмнәреннән дә мәхрум итте. Мәсәлән: 1. Икскида боз китүне озату. 2.Мортай. 3. Сабан туе. 4.Чөмән буе. 5. Җуа җомгасы. 6.Түбәрәк тал. 7.... 8. Корбан сую. Көзен каз өмәләре, бер-берсен кунакка чакыру. Гомумән, авыл халкының тормышын һәм культурасын җимерде. Аларны кайгы-хәсрәткә салды; алар арасындагы аңлы һәм алдынгыракларын илтеп таш капчыкка салды. Бу үзгәртеп кору (коллективлаштыру) бик зур борылыш булды. Крестьянның җирен-суын, атын-абруен-симәнәсен, эш коралларын һәм барлык ашлыгын тартып алу, өстәмәсенә гомумиләшкән малларга фермалар җиткерү өчен сарайларын сүтеп алу крестьяннарга кайгы-хәсрәт һәм зур ачу тудырды, моның белән кешеләрнең сүтелгән урыннары ачык калып урамнарның яме бетте, авылның матурлыгын җимерде. Бөтен маллары, тавыгына тикле учетка алынды. Аларга төрледән-төрле налоглар-заемнар салынды, ит-сөт-йомырка тапшыру һәм башкалар. Өстәмәсенә, мондагы ирләр бозык канлы, киләчәккә таза-чиста канлы балалар табу өчен хатыннарга чиста канлы ирләр китереләчәк дигән төрле агитациялар таралды. Болар бөтенесе крестьянны утка-суга салды һәм ачу тудырды. Гомергә бер тугандай яшәп килгән авыл халкын бер-берсенә дошманнаштырды.

Бу вакытта дәүләт карарларын үтәү өчен мәктәп-училищеләр бетереп кайткан кешеләр авылда юк иде, фәкать кызыл армиядә яшьләрне тәрбияләп, аң-белем биреп кайтардылар һәм алар, укытучылар белән бергә дәүләт карарларын үтәү өстендә эш алып бардылар. Алар авыл советы депутатлары һәм исполком членнары булдылар.

1926 нчы елда армиядән Тухбатуллин Габдулла кайтты, ул авылга нык кына яңалык кертте. Крестьяннар комитеты төзеде һәм аның председателе булды; игеннәрнең уңышын арттыру буенча халыкка белем бирә башлады (сортировка алып кайта). Шулай ук, республиканың төрле урыннарында коллективизация булуын һәм бездә дә булачагын халыкка аңлата башлады.

Бу аңлату халыкка ошамады, бигрәк тә авыл куштаннарына, һәм аңа каршы килә башладылар.

Тора-бара 1929 нчы елның август аенда 7 кешене Тухбатуллинга ияртеп кулга алдылар. Алардан соң тагын берән-берән кулга алынучылар булды. Гомумән, 12 кеше кулга алынып 5сен аттылар (Тухбатуллин Габдулла, Давлетшин Нури, Ситдиков Закир, Багаутдинов Карами һәм Сайфуллин Рафыгетдиннәр атылды).

1929нчы елның азагында, 1930нчы елның башында колхозга берләштерү буенча бездә дә эш башланды.

Безгә Мәскәүдән 25нчеләрдән *(двадцати пяти тысячники)* Кондаков Ахметҗан дигән кеше килде. Аны, килү белән, авыл куштаннары үзләре янына алдылар; һәр көнне аны

кунакка чакыру башланды. Шулай ук аның белән бергә, укытучы –алдынгы кешебез, дип, Елизавета Смирнованы чакырдылар. Алар һәр көн ашка йөри торгач танышып киттеләр һәм өйләнешеп тә куйдылар. Кондаков һәр көн исерек, колхоз турында уйламый. Ә авыл халкына шул гына кирәк, чөнки колхозга керү өчен тиешле аңлату алып барылмады. Тора-бара районнан килеп 15нче мартта мәктәпнең олы бүлмәсенә барлык кешене чакырып өсләреннән бикләп, кем керә – аны ачып керттеләр, шулай иртәдән төнгә тикле язалап гаризаларга кул куярга мәҗбүр иттеләр.

1930 нчы ел 29 нчы март, Сталинның “уңышлардан баш әйләнү”дигән мәкаләсе басылып чыга, колхозларга көчләп кертмәскә дип языла.

Шушы газетаны алу белән, барлык халык колхоздан чыгу өчен гариза китерә һәм чыгалар, 100%. Тик Кулячев Гатау белән Башаров Госмән кала, чөнки гаризаларны Кулячев Гатау үзе җыя.

Башаров Госмән 1925-1930 тикле Камай волосполком председателе була һәм ул Советларның 6 нчы съездыннан 7 нче съездына тикле Татарстан Верховный Советы депутаты була һәм Камай волосына кергән барлык авылларда колхоз төзү һ.б. аның өстенә төшә.

Кулячев Гатауның бер үзе колхозда калуы **колхоз 1930нчы елны төзелде** дип регистрациягә кереп калды.

Колхозлар таралгач, халык элеккечә яши башлап, җыйналган эш коралларын кире алалар.

Авылның кайбер кешеләренә тагын йөрәк керде, колхозга кертүдә эшләгән авыл советы членнарыннан һ.б. ачу алуны күздә тоталар. Нәтиҗәдә, 1930 ел апрель азагында сал эшләгәндә эшләгән җирендә авыл советы исполком члены Садриев Миннәхмәтне вахшиларча балта белән чабып үтерәләр.

Башаров Госмәнгә дә куркыныч туа башлый, аны якын дуслары Иж заводына төнлә белән алып чыгып китәләр.

Көз, ноябрь айларында (25 ендә) кич сәгать 9-10 да авыл советына Шарифуллин Габденурны чакыралар. Ике чакыруга ул килми. Өченче чакыруда төшә; кайту уңаенда тау төшкәндә Хуҗәхмәт сушилкасында тотып алалар һәм буып үтереп, авылдан 3 км ераклыкта имән агачына илтеп асып куялар.

1931 нче ел башында авылда колхоз төзү өчен Бондюг заводы коммунистлары һәм профсоюз оешмасы авылны шефка ала һәм авылга вәкил итеп үзләреннән Гимазтинов Салахны җибәрәләр. Ул килгәч организация комиссиясе төзелә. Аның председателе – мәктәп директоры Файезов Магсум була, членнары Гимазтинов Салах, Кулячев Гатау, мәктәпнең хезмәт укытучысы Хасанов Ислам һәм авыл советы члены Газизова Татҗибәләр була.

Гаризалар җыялар, һәм 31 гариза кергәннән соңында 1931 нче ел 10 нчы мартта беренче җыелыш була. Миңа Файезов Магсум диктовкасы белән беренче протокол язарга туры

килде. Заводтан Мурат Хуҗин һәм Зия Ибатуллиналар килә, җыелышта идарә составы сайлана 5 кешедән һәм ревкомиссия 3 кешедән, председатель  итеп колхозга килүчеләр үзләренең вәкилен- Гимазтинов Салахны калдыралар. (Ул 25нчеләрдән була.) Идарә составы: Исмагилов Ислам, Газизова Татҗибә, Гиздатуллин Набиулла һәм Хасанов Исламнар сайлана. Ревком: Кулячев Гатау, Шарипов Минхач һәм Багаутдинова Рахимәләр сайлана. Счетовод булып Гиздатуллин.

1932 елда Кулячев Гатауның соравы буенча ревком председателе итеп Кашапов Хаким (укытучы) сайлана. Бу вакытта авылда 598 хуҗалык була, болардан: 6 хуҗалык - Магнитогорскига җибәрелә, 6  хуҗалык - үзләрен чыгарып җибәрәләр авылдан, 12 хуҗалык – Тихигора артеленә барып керә, 3 хуҗалык – Алабуга маслотрест заводына китәләр, 2 хуҗалык – Монай колхозына керәләр. 562 хуҗалык үзебезнең  колхозга кереп, 1935 елда 1 июльдә коллективизация ... дип рапорт бирелә. 7 хуҗалык керми кала. Колхозның беренче счетоводы итеп  Гиздатуллин Мулланур алынды. Язга чыгу белән аерым хуҗалыклардан кергән җирләрнең буразналары көрәк белән төзәтелде. Бондюгтан һәр вакыт килеп тикшереп тордылар (Сахабудтинов).

1931 ел 18/IX дә ферма өчен 64 сыер, 1 үгез кайта, аларны ябу өчен бер төрле урын булмый, Шибаев Фардинең тыкырыгына (авыл советына каршында) урнаштырыла; соңынчы вакытта Шайгаллямов Закир һәм Сиракаев Мифтах милегенә урнаштыралар. Күп тә үтми, Шайгаллямов Закир милегенә  10/X дә ут төртәләр. Колхозчылар байтак кына кеше булу сәбәпле, ут төрткән иске мунча җимерелә, ут сүндерелә.

Миңа, сыерлар кайткан көннән, аларны кабул итеп, 1/XII гә тикле ферма җитәкчесе булып эшләргә туры килде.

1931 нче ел августта Башаров Госмәнгә кайтуын сорап хат белән Зайнутдинов Фаттахны җибәрдек. Госмән абый безнең үтенечне кабул итеп, Зайнутдинов белән кайтып, бергә эшли башладык һәм  1/XIIдән зав.ферма булды, мин отчет төзү өчен конторга кайттым.

1931 ел сентябрь азагында төрмәдән качып кайткан Гимазтинов Г-ны тотарга төшкәч Гимазтинов Салах белән икебезгә аттылар. Бу турда гаепле кеше ачыкланмады. Бу безгә беренче удар булды һәм арабызда теге яклы дошман бары беленде.

1932 ел гыйнварда Гимазтинов Салах райисполкомга алынды; урынына Хайрутдинов Хуҗа сайланды.

1932 ел февральдә хисапчы Гиздатуллин китте. Хисапчы булып авыл советы секретаре Давлетшин Гәрәй керде.

1932 ел 20 октябрь тирәсендә конторга ут төрттеләр. Районнан прокурор, НКГБ начальнигы Козров, милиция бүлеге начальнигы Хурматуллин, алар мине чакырып, конторны ачып керсәк, шкаф ватык, бөтен книгалар мич алдына өйелгән һәм яндырылган. Ләкин книгаларның кырлары янган, эчтә бөтен язулар исән. Мин, книгаларны тулысы белән восстановить итә алабыз, дидем.

Прокурор: ”Алайса Давлетшинның махинациясен табарга була, дисез?”
Мин: ”Давлетшинның бер махинациясе юк”,- дидем.
Начальник НКГБ: “Сез бергә эшләгәнсез, шуңа яклыйсың”,- диеп миңа каты гына кычкырды.
Мин һаман үз сүземдә: “Безнең контор дошманнар тарафыннан яндырылган”, - дидем.
Прокурор: “Нәрсәдән чыгып әйтәсез?” – диде.
Мин: “Шкафта 586 ат паспорты бар иде (ул вакытта атлар строго учетта), нишләп аның берсе дә юк, хоть берсенең кырые булса да калырга тиеш. Алар урланган дип хисаплыйм,” - дидем . Алар берсенә берсе караштылар.
“Икенче шаһитым бар, - дидем. - Менә штампа агачы. Әгәрдә штампасы янган булса, ул да янар иде, я, булмаса, агачы көяр иде, - дидем, штампасы урланган, - дидем, һәм агачы өстенә бармак бите хәтле кыягаз салып шырпы белән яндырып күрсәттем; агач көйде. Бу тулысы белән ышанычлы факт “,- дидем. Алар миңа ышана башладылар.
Өченче шаһитым барлыгын әйттем. Алар аңлатырга куштылар.
“Минем җир карталарын эшләү өчен готовальням бар иде, ул 32 төрдән металлический приборлардан тора, яна торган түгел, аның берсе көл арасыннан чыгарга тиеш,- дип көлне актардым, - юк бит”- дидем, - урланган”,- дидем.
Шулардан соң акт яздылар; дүртебез дә кул куеп, Давлетшинны азат иттеләр.
...1933 ел мартта ат паспортларын Агрыздан табып китерделәр.
Бандитлар авылда яшәп кышын Бәзәкәдә чыгалар. Алар дүртәү булып, атаманнары Зәй районы Карамалы авылы Хузин Дамир була, берсе Мамадыш районыннан, берсе Сәйтәктән, берсе билгесез.

1933 ел августта бу группаның умарталык каравылчысы янына чыгып тамак туйдырулары турында сигнал булды. Без, бер көнне 10 кеше, төнлә белән умарталыкны урап алдык, һәм килгән яктан ст.лейтенант Корпаков белән сукмактан йортка керергә булдык, сукмактан барганда мин, борылып Корпаковка, без ялгыш барабыз, дидем. Ул, ни өчен, дип сорады. Мин, тәрәзәдән сукмакны искәртеп торачаклар, дидем. Ул, үзеңчә алып бар, дигәч, мин аска таба 2-3 адым атладым, Корпаков бер атлавы булды, арттан атып та җибәрделәр. Корпаков янындагы умарта түбәсен ядрәләр кубарды һәм Корпаковның шинель итәге тишелгән иде. Корпаков йөгереп чыкты, артта калдырган кешегә пистолеты белән яңагына сукты. Артка куйган кешебез ГПУ да штаттан тыш эшче булып эшләүче Губайдуллин Габдулла иде. Беренче атучы да шул иде, тик мин әйтүгә ышанмаганнар иде, ул чыгып качты.

1931 ел беренче комсомол оешмасы төзелә. Коллективизация вакытында бик яхшы эшлиләр иде. Комсомоллар арасында бу вакытта эчәргә юл куелмый. Ләкин авыл халкы комсомолларга беренче дошман итеп карый иде. Комсомолец Гильфанов Фаттах эчкәне өчен бригадир эшеннән алынды. Бондюг заводына агач чыгаручыларга бригадир итеп 1934 нең гыйнварында Гильфанов Фаттахны җибәрдек. Шимбә көн ялга кайтканда алган спиртларын эчәләр, Фаттахка да эчертәләр, син яшь кеше, дип күбрәк тә бирәләр; ул исерә һәм йоклый. Кайтырга чыккач таш күпер тамагында итеген салдыралар. Көн 30 градус салкын була. Авыл кырыена кайткач, уятып, итеген кигерәләр. Икенче көнне болниска бара – аягын кисәләр. Комсомолдан шулай үч алалар.

Авылда каршылыклар бетми. 1936 ел 16/XIIдә фермада малларны агулыйлар. Бу вакытта тикшерсәләр дә гаепле кеше табылмый. Фәкать 1957 нче елны билгеле була: 12 сыер, 6 баш тана, барысы 18 баш. Ул вакытта саламны парлап известь кушып бирелә иде. Известь урынына Бондюгтан хлор известь алып кайтып биргәннәр. Бу кешеләргә нәрсә булса әйтер идем, ләкин аларның милегендә кычыткан-әрем генә үсә; гонаһассыз малларның язмышы алардан да читкә китмәгән.

1941 елда сугыш чыгуын комсомол секретаре буларак миңа аңлатырга туры килде. Һәм 1945 ел сугыш тәмам булуын да партия оешмасы секретаре буларак миңа аңлатырга туры килде.

Фронтка 760 лап кешене җибәрергә туры килде. Төрле фикердә китәргә уйлаучылар булды, кайсылары китмәде, үч алырга яки магазиннарны ватып китәргә теләүчеләр булды. Ләкин яхшылык белән аңлаткач ул уйдан кире кайттылар.

Бигрәк тә авыр булды 26/YIII, ул көнне 73 кеше китте: колхоз председателе, ярдәмчесе, завхоз, зав.производства, 7 бригадир. Фронтка барудан баш тартучылар да булды. Алар 5 кеше Елабуга төрмәсеннән башка кайтмастай урынга киттеләр. Ике кеше, үзләренең хыянәте өчен, полевой суд карары белән атылдылар.

Комсомол-партия оешмасына фронттан 50гә якын хат һәм Берлиннан колхоз идарәсенә бер посылка килде. Хатлар арасында партизан отряды командирыннан 2 хат килде. Ул колхозчыбыз Ганиев Хабибулла Мехаматша улының Гарай булуын әйтеп язды. Соңгы хаты 1944 елның апрелендә язылган иде: “Тиздән алдынгы частьларга кушылабыз, кушылу белән авылыгызга җибәрәбез. Ганиев Х.М. белән мактанырга хаклы сез!”- дип язды.

Авылда колхозчылар арасында төрле формада яшәргә уйлаучылар булды. Ләкин аларга юл куелмады. Колхозчылар бик авыр хәлдә яшәделәр, барлык налог-заемнарын түләделәр, итен-сөтен-йон-йомыркасын, һәр барсын түләделәр, өстәвенә, бөтен сугыш дәверендә танклар колоннасына 1262 мең акча бирделәр.

*Бу әтием Хөснетдинов Габделхакның кулъязмасы. Бу язма колхоз төзелүгә 60 ел тулу уңаеннан язылган доклад булган.*

*Гузель Габдуллина (Гильфанова) 2016 ел*




*Это фото со времен образования колхоза в нашей деревне (1930-31 годы).*
*Тогда в колхозе было несколько бригад и даже в одной деревне 2 колхоза им. Сталина и им. Ворошилова*



*Это комиссия по организации колхоза в деревне.*

*Слева впереди сидит Башаров Госман, а справа стоит второй – Габдулхак Хуснутдинов.*